

АЛТЫН ГРАМОТА

ТАТКНИГОИЗДАТ · 1955



АЛТЫН ГРАМОТА

СССР ХАЛЫКЛАРЫ ӘКИЯТЛӘРЕ

ТАТКНИГОИЗДАТ
Яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе
Казан 1955

Редакторы
Сахаб Урайский

Тышлык художнигы
И. Колмогорцева

КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН

РЕДАКЦИЯДӘН

Фольклорда, халык әкиятләрендә диннең, чиркәүнең, җыен юк-барга ышануларның кискен фаш ителүен күп очратырга мөмкин. Халыкның аек, тапкыр, үткен акылы, аның юморы Советлар Союзы халыкларының күп төрле әкиятләрендә күренә.

Халык аларда руханиларга күп файда бирә торган «могҗизалар»дан көлә; шәхси баюлары өчен барын да эшләргә хәзер торган попларның, муллаларның һәм раввиннарның гадәттән тыш комсызлыгын ачып сала; барын да кичерү, инсафлылык турында инҗил васыятьләрен үтәүне халыктан таләп итеп тә, аларны үзе бик аз үтәүче чиркәүне фаш итә.

«Мужик ничек оҗмахка барган» дигән әкият бигрәк тә кызыклы. Бу әкияттә теге дөньяга, оҗмахка ышандыруга, ярлы кеше гаделлекне, янәсе, ахирәттә табар, дигән өметләргә халыкның тапкыр һәм ironияле карашы күренә. Бу әкияттәге оҗмах — мужикны кыерсыта һәм талый торган җиргә бик нык охшаган. Анда да шул ук гел эчүчелек белән шөгыльләнүче, тупас һәм ялкау начальниклар, ә иң зур начальник — мәгънәсез һәм надан алла. Ул мужикка ярдәм итү түгел, хәтта кәгазьгә кул да куя белми. Димәк, мужиклар аллага һәм суфиларга түгел, ә үз-үзләренә генә ышанырга тиешләр, диелә халык әкиятләрендә.

Бу китапка 1954 елда детгиз чыгарган «Караңгылыктан яктылыкка» дигән русча җыентыкка кергән СССР халыкларының әкиятләре тупланды. Ике әкият 1954 елда Таткнигоиздат чыгарган «Татар халык иҗаты» һәм «Азербайҗан әкиятләре» дигән китаплардан алынды.



ҚӘҖӘ ТӘҚӘСЕН ҚУМУ

Рус әкияте

Яшәгәннәр, ди, бер карт белән бер карчык. Боларның бер балалары да юк икән. Асраганнар, ди, алар бары бер кәҗә тәкәсе генә. Карт бернинди дә һөнәр белмәгән, чабата үреп, шуның белән генә тамак туйдырган. Кәҗә тәкәсе картка бик ияләшкән: карт кая гына бармасын, ул аның артыннан йөгерә икән. Көннәрдән бер көнне карт урманга юкәгә китә, аның артыннан кәҗә тәкәсе дә ияреп бара. Урманга килгәч, карт юкә каезларга тотына, ә кәҗә тәкәсе, әрле-бирле йөреп, үлән ашый башлый. Шулай ашаган-ашаган да алгы аяклары белән кинәт көпшәк җиргә баткан, аннары җирне казырга тотынган һәм аннан бер котелок алтын казып чыгарган. Кәҗә тәкәсенең җир казуын күргәч, карт тиз генә аның янына

килгән һәм алтынны күргән. Ул шулкадәр шатланган, юкәләрен ташлаган да, алтын акчаларны җыеп, өенә кайтып киткән. Карт боларның барысы турында да карчыгына сөйләгән.

— Я, карт,— дигән карчык,— күп еллар буе ярлылыкта яшәп интеккәнебез өчен, бу хәзинәне алла безгә картлык көнебез өчен биргәндер. Хәзер бик рәхәтләнеп яшәрбез инде!

— Юк, карчык,— дигән аңа карт,— бу акчалар безнең бәхеткә түгел, кәҗә тәкәсе бәхетенә табылды. Хәзер кәҗә тәкәсен үзебезгә караганда да кадерләбрәк тотарга кирәк!

Шул вакыттан алып алар кәҗә тәкәсен бик кадерләгәннәр, аны яхшылап караганнар, үзләренең дә тормышлары әйтеп бетергесез яхшырган. Карт чабатаны ничек үрүләрен дә оныткан, бернинди кайгы-хәсрәтне белмичә яши башлаганнар болар.

Менә берничә вакыттан соң кәҗә тәкәсе авырый башлый һәм үлеп тә китә. Нишләргә? Карт бу турыда үзенең карчыгы белән киңәшергә тотына.

— Әгәр кәҗә тәкәсен этләргә ташласак, моның өчен алла каршында да, бәндә каршында да гөнаһлы булырбыз, бөтен бәхетебез кәҗә тәкәсе аркасында килде бит. Поп янына барыйм да кәҗә тәкәсен барлык христиан мәетләрен күмгән кебек күмәргә сорыйм.

Карт җыенган да поп янына киткән һәм килеп аңа баш игән:

— Исәнме, батюшка!

— Исәнме, газизем. Нинди йомышың бар?

— Мин синең катыңа бик зур үтенеч белән килдем, батюшка. Минем өемдә зур бәхетсезлек булды бит: кәҗә тәкәсе вафат булды. Сине җеназага чакырырга килдем.

Бу сүзләрне ишеткәч, поп бик нык ачуланган, картның сакалыннан эләктереп алып, аны өй буенча өстерәп йөрергә тотынган:— Эх син, гөнаһ шомлыгы! Нәрсә уйлап чыгардың? Сасы кәҗә тәкәсен күмәргә дисең!

— Батюшка, ул кәҗә тәкәсе бөтенләй православный диярлек иде бит: ул сиңа ике йөз сум бирергә кушып калдырды.

— Ах син, карт тиле,— дигән поп аңа,— мин сине кәҗә тәкәсен күмәргә чакыруың өчен түгел, әлегә кадәр аның үлүе турында белдерми торуың өчен кыйныйм: бәлки ул әллә кайчан үлгән булгандыр!

Поп мужиктан ике йөз сумны алган да:

— Бар, тизрәк отец дьякон янына йөгер, әзерләнсен: хәзер кәҗә тәкәсен күмәргә барабыз,— дигән.

Дьякон янына килгән дә карт болай дигән:

— Хөрмәтле дьякон, авырсынмыйча гына безгә җеназага кил әле!

— Синең кемең үлде соң?

— Кәҗә тәкәсе үлеп китте. Сез аны белә идегез бит!

Әй тотынган дьякон картның колак төпләренә кундырырга!

— Кыйнама син мине, дьякон әфәнде,— дигән карт,— кәҗә тәкәсе православный кебек үк иде бит: үлгән чагында ул үзен күмгән өчен сиңа йөз сум бирергә әйтеп калдырды.

— Ах, син карт юләр!— дигән дьякон моңа,— нигә син аның православный булып үлүен әллә кайчан хәбәр итмәдең? Бар тизрәк дьячокка: кәҗә тәкәсенең рухына багышлап чаң суксын!

Дьячок янына йөгереп килгән дә карт:

— Бар, кәҗә тәкәсенең рухына багышлап чаң сук.

Дьячок та ачулана, картның сакалыннан йолкырга тотына.

Карт:

— Җибәр мине,— дип кычкыра,— кәҗә тәкәсе православный иде: күмгән өчен сиңа илле сум бирергә кушты!

— Әлегә кадәр нишләп тордың син, нигә күптән әйтмәдең миңа бу турыда, әллә кайчан чаң сугылырга тиеш иде.

Дьячок шунда ук манарага йөгереп менгән дә, бик каты итеп, барлык колоколларга бәрергә тотынган. Поп белән дьякон карт өенә килеп кәҗә тәкәсен җыештыра башлаганнар. Аны табутка салалар да зиратка илтеп кабергә күмәләр.


Менә бу турыда мәхәллә кешеләре үзара сөйләшә башлаганнар. Попның кәҗә тәкәсен христианнарча күмүе архиерейга да ишетелгән. Поп белән картка җәза бирү өчен архиерей аларны үзенә чакырта.

— Ах сез, динсезләр! Ничек сез кәҗә тәкәсен күмеп йөрергә батырчылык иттегез?

— Ул кәҗә тәкәсе,— дигән карт,— башка кәҗә тәкәләре кебек түгел иде: үләр алдыннан ул сезгә — изге атага — мең сум бирергә кушты.

— Нинди ахмак карт син! Мин сиңа кәҗә тәкәсен күмгәнең өчен түгел, аны вакытында өшкертмәгәнең өчен җәза бирәм!

Архиерей мең сумны алган да карт белән попны өйләренә кайтарып җибәргән.



ПОП БЕЛӘН ПОНОМАРЬ

Рус әкияте

Пономарь, попның кар базына төшеп, каймак ашарга иялэшеп киткән. Уразамы, түгелме, каймакны базга куя күрмә: пономарь, ата мәче кебек, чөмерә дә бетерә. Бервакыт поп пономарьга:

— Әгәр тотсам, юк итәчәкмен!— ди.

Пономарь поп алдында акланырга уйлый. Пасха җиткән. Кадер кичәсендә пономарь базга төшеп күбенгәнче каймак ашый да кашыкны үзе белән эләктереп чыга. Гыйбадәткә кадәр чиркәүгә бара да спаситель белән Николай-угодникның иреннәренә каймак сөртә бу.

Менә халык иртәнге гыйбадәткә җыела. Поп укый башлый. Һәм, аллаларга караса, ни күрсен, спаситель белән Николай-угодникның мыекла-

рыннан каймак саркып тора. Поп бик нык ачулана да кадило белән Николайның ипи шүрлегенә менеп төшә.

— Мин сезне, әрәмтамаклар, ничек каймак ашарга өйрәтермен!— дип акыра.

Кичен пономарь белән поп гайсаны искә төшереп дога кылганда, поп болай ди:

— Гафу ит, туганкай, каймак ашаучыны мин син дип уйлаган идем.

ШАХСЕВЕН ХАҖИЕНЫҢ ЭТЕ

Азербайҗан әкияте

Шахсевен дигән авылда бер бай хаҗи яшәгән. Аның бик күп алтыны, көмеше, көтү-көтү сарыклары, сыерлары, үгезләре һәм атлары булган. Аның көтүләре үзенең иркен Шахсевен болыннарында йөргәннәр.

Хаҗиның көтүләрен саклый торган бик акыллы, батыр эте дә бар икән. Бу эт сарыкларның сакчысы, атларның дусы булган. Хаҗи аны бик яраткан һәм шуңа күрә күз алмасы кебек саклаган.

Көннәрдән бер көнне хаҗи, йокысыннан уянгач, кадерле этенең үзе янында ук үлеп ятканын күргән. Эт бер зур сөяк йоткан һәм үлеменең сәбәпчесе дә шул сөяк булган.

Хаҗи зур кайгыга төшкән. Үзенең турылыклы, батыр этенә карап, кайнар күз яшьләрен агызган.

Ул бик озак тынычлана алмаган. Этнең үләксәсен ак кәфенгә төрергә кушкан һәм гаять атаклы, мөгътәбәр кешеләрне күмгәндәгечә, этне кадер-хөрмәт белән тантаналы рәвештә күмдергән. Мулла аның кабере өстендә өч көн, өч төн

туктаусыз коръан укырга тиеш булган. Хаҗи үзенең акыллы этенә багышлап, аның җидесен уздырган һәм җиде көн буе барлык ярлыларны, хәерчеләрне ашаткан, аларга сәдакалар өләшкән.

Бер заман бу хәбәр олуг имам хәзрәткә дә ишетелгән.

Олуг имам хәзрәт, акылыннан шашар дәрәҗәдә куркып, башына көл сипкән, күлмәкләрен ерткалап бетергән.


— Пәйгамбәребезнең дине аяк астына салып тапталган, пычракка аунатылган! Изге законнар мәсхәрә ителгәннәр, алладан көлгәннәр! И бозык бәндәләр! Эт үләксәсен мөселман йолалары белән күмәргә, аның кабере өстендә коръан укырга батырчылык иткән бәдбәхетләр йөз мең тапкыр үлемгә хөкем ителергә лаеклылар!

Имам атка атланган да хаҗи янына киткән. Ул аны динне мәсхәрәләгәне, диннән көлгәне өчен бик каты җәзага тартырга карар иткән.

Имам киләсен хаҗига алдан ук әйтеп куйганнар. Ул тиз генә үзенең көтүеннән иң симез илле сарыкны сайлап алырга кушкан да үзе имамны каршы алырга киткән. Хаҗи, имам алдында җиргә кадәр баш иеп, аның киемнәрен үпкән һәм болай дигән:

— И олуг имам хәзрәтләре, безнең динебезнең терәге һәм намусы! Ата-аналарым синең аякларың астында корбан булсыннар. Мин юаш колыңның кайгысын тыңлап карачы. Минем иң турылыклы, данлыклы Боздарым, йөрәгемнең терәге, көтүләремнең сакчысы, дошманнарның котын алып торучы этем үлде! Ул чын мөселман иде, барлык муллаларны, имамнарны бик хөрмәтли торган иде; үләр алдыннан ул хәтта сиңа иң симез илле сарык бирергә васыять әйтеп калдырды. Менә ул сарыклар!

— Эх! Сез, алла бәндәләре! Нигә син аны эт дип кимсетәсең! Син аны минем туганым, минем дусым дип әйт!— дип кычкырып җибәрә имам.— Күрсәтче миңа аның каберен, аның рухына багышлап, үзем коръан укыйм әле мин!



МУЖИК НИЧЕК ОҖМАХКА БАРГАН

Рус әкияте

Ниндидер бер патшалыкта, ниндидер бер дәүләттә, Олонецк губернасы, Петрозаводск өязенең Толвуй волостенда шундый хәл була. Язгы Микола җитә, ә үлән юк та юк: үсмәгән.

— Нишләргә инде хәзер,— дип кычкырышалар крестьяннар.— Без һәрвакыт Миколага ышана идек, ул үлән алып килергә тиеш иде, ә хәзер менә тот капчыгыңны.

Җыенга җыелганнар, ди, мужиклар бер заман. Тегеләй киңәшкәннәр, болай сөйләшкәннәр. Уйлаганнар болар Микола өстеннән аллага жалоба белән барырга. Поптан аллага үтенеч язуны сорыйлар икән, ә поп әйтә, ди:

— Сез нишлисез, православныйлар! Безгә,

гөнаһлыларга, изге Николай-чудотворец өстеннән жалоба бирү килешәме соң?

Әмма крестьяннар попны үтенеч язарга мәҗбүр итәләр һәм Саваоф дигән алланың үзе янына чиркәү старостасын җибәрергә булалар.

Бара, бара икән староста һәм үзе уйлый икән: ничек итеп соң күккә күтәрелергә? Торналар очканын күрә бу, бер торна өстенә утыра да күккә күтәрелә, алланың канцеляриясенә килсә, староста күрә: капка төбендә апостол Петр швейцар булып тора. Апостол Петр старостадан тегенемоны сораша да, ишекне ачып, аны канцеляриягә кертә. Староста, күк канцеляриясенә кергәч, күрә: Саваоф зур өстәл артында утыра, чырае сытылган, әллә ачулы, әллә пахмельдән соң башы авырта инде, башын тоткан да уйга калган. Кирилл белән Мефодий писарьлык хезмәтен башкаралар икән. Алар да шунда ук утыралар. Машинистка булып Мария Магдалина эшли. Архангел Михаил ишек төбендә тора, анысы курьер икән. Староста чукына, бик түбән итеп башын ия, «исәнмесез» дияргә дә өлгерми, Мефодий аның янына йөгереп килә дә:

— Эш нидә, мужичок, җирдә нинди яңалыклар бар?— дип сорый.

— Менә шулай,— ди староста,— Толвуй мужиклары мине алла янына жалоба белән җибәрделәр. Быел Микола үлән бирмәде, терлекләргә ашатырга бернәрсә дә юк.

Мефодий жалобаны ала, әйләндереп-әйләндереп карый да аллага суза.

— Менә,— ди Мефодий,— Толвуй мужиклары Микола өстеннән жалоба язганнар.

— Нәрсә миңа сузасың?— ди алла.— Минем хәреф тә танымаганны беләсең бит. Әлифбаны үзең чыгардың — үзең укы.

Мефодий үтенечне ахырына кадәр укыган. Алла йодрыгы белән өстәлгә шундый итеп суккан, Мария Магдалина хәтта урыныннан сикереп торган, ди. Архангел Михаил куркуыннан өстәл янына йөгереп килгән, апостол Петр капкаларны ачкан, староста идәнгә утырган.

— Микола-чудотворецны чакырырга!— дип кычкыра алла.

Архангел Михаил аны эзләргә йөгергән.

Менә Микола-чудотворец килгән.

— Нәрсә бар? — дип сорый икән.

— Ничек «нәрсә бар?» — дип ачулана алла.— Менә Толвуй мужиклары синең өстеңнән жалоба язганнар, үлән бирмәгәнсең син аларга, терлекләрен ашатырга бернәрсәләре дә юк, ди. Син бит үлән алып барырга тиеш, православный христианнар сиңа өметләнәләр, ә син аларны алдагансың, шуның белән үзеңә дә, безгә дә ышанычны югалткансың. Мужиклар безгә бөтенләй ышанмаячаклар бит. Поплар болай да доход аз дип зарланалар.

— Ә миңа нәрсә,— ди Микола,— мин гаепле түгел. Ни өчен Георгий-победоносец чишмәләрне җибәрмәгән? Чишмәләр булмагач, үләнне ничек үстерим мин?

Шулай дигәч, борылган да бу Варвара-великомученица янына, башлаган сырасын эчәргә киткән.

— Георгий-победоносецны монда чакырырга,— дип акырган алла яңадан.

Менә ак атка атланып Георгий-победоносец килеп җиткән һәм шул көенчә канцеляриягә дә кергән.

— Нәрсә булды, изге ходаем?— дип сорый икән Георгий.

Әалла аңарга:

— Нигә болай булды бу?— ди.— Ни өчен син вакытында чишмәләрне җибәрмәдең? Синең аркада Микола үлән үстерә алмаган.

— Ә миңа нәрсә,— ди Георгий,— мин гаепле түгел. Ачкычларның мөдире алла бәндәсе Алексей бит. Ул ачмады, су бирмәде, ә мин чишмәләрне каян алыйм?

Алла тагын да ныграк котырынган. Ике йодрыгы белән тәхетенә suга икән, икенче өстәлләр дер селкенәләр, ди. Мария Магдалина «оҗмах буенча боерык» диясе урынга «оҗмах буенча койрык» дип язган.

— Хода бәндәсе Алексей кая, хәзер үк аны минем янга китереп җиткерегез,— ди алла.

Архангел Михаил Алексейны эзләргә дип йөгереп чыга һәм баскычтан чак кына егылмый, йөри торгач, аны көчкә генә эзләп тапкан. Алексей, кичтән исерек булып, ачкычларын югалткан икән дә, ул шуларны эзләп йөри икән, ди. Алексейны күрү белән, Архангел Михаил аңа:

— Тиз бул, алла янына йөгер!— дип кычкырган, ди.

Хода бәндәсе Алексей алла янына килә дә, «нәрсә бар?» диясе урынга: «Сыра бармы?»— ди икән. Бар да шаркылдап көләләр. Алла үзе дә елмаеп куя. Үз бәндәсе булгач, алла ачуланмыйча гына:

— Нигә син суны ачмадың?— дип сорый.

— Мин,— дип җавап бирә Алексей,— суны ачкан идем дә, кайдан аксын соң ул: Василий-капельник бер тамчы да тамызмады. Ә су бит тамчыдан башланырга тиеш,— ди.

Алла хәтта аягын тибеп бик каты ачулана да Василий-капельникны чакырырга куша.

Василий-капельник алла янына килүен кил-

гән, ди, ләкин «әни» дип тә әйтерлек хәле юк икән, ди. Алар Николай-чудотворец, хода бәндәсе Алексей белән Варвара-великомученицада төне буе эчеп утырганнар икән.

Алла аның исерек икәнен сизгән дә:

— Син нәрсә болай? Үзең ылкынганчы эчкәнсең, ә кешеләргә бер тамчы су да тамызмагансың!

— Ә миңа соң нәрсә,— ди Василий-капельник,— мин гаепле түгел. Син үзең ялгыштың: иң мөһим эшкә хатын кешене куйдың. Барысы өчен дә Авдотья-плющиха гаепле, аңа ныграк тырышырга кирәк иде, ә ул бөтенләй эшләмәде. Кайдан алып тамызыйм соң мин суны? Юкка гына баш әйләндерәсең.

Алла тагын да яманрак ачуланды һәм Авдотья-плющиханы таләп итте. Авдотья-плющиха килә. Алла аякларын тыпырдата, йодрыклары белән суга:

— Син тегенди-мондый, нәрсә эшлисең! Ә-ә-ә! Сез Варвара-великомученица белән компания ясауны гына беләсез. Барлык апостоллар һәм пәйгамбәрләр үзләренең эшләрен оныттылар, сезгә баралар да сыра эчәләр. Бөтен эшне син боздың!

— Нәрсә син миңа зәһәрләнәсең, мин гаепле мени монда,— ди тегесе.

Әй тотынды, мин сиңа әйтим, кыздырырга — аллага эссе булып китте

— Үзең урнаштырган булсаң да, ул тәртипләрне син үзең белмисең. Кар, яңгыр белән Илья-пәйгамбәр идарә итә ич. Аңардан сора... Ә Варвара белән мине апостолларга бәйләп шелтәләргә хакың юк. Үзең дә еш кына миңа кергәлисең бит. Барыгыз да бер! Юкка мине борчыма: өйдә яшь балаларым бар минем.

Алла, бераз уйлап утыргач, Илья-пәйгамбәрне чакырырга җибәргән. Чиркәү старостасы күк күкрәгәнен ишетә. Менә канцеляриягә Илья-пәйгамбәр килеп керә.

— Сез үзегез гаепле, ходаем,— ди Илья-пәйгамбәр.— Җәй бит сезнең әмерегез белән яңгырлы булды, көзге Егорьягә кадәр карны кайдан алыйм мин?— ди.

— Ә син ни өчен соң печән өстендә яңгыр яудырдың!— дип сорый алла моңардан.

— Печән чапканда яңгыр яудырырга кирәк, дип, син үзең миңа әйттең бит.

— Ахмак!— ди алла.— Мин бит синә яңгырны сораган чакта яудырырга, дидем, ә син печән чапканда яудыргансың.

— Ә-ә-ә, туган!— дип җавап бирә Илья.— Шулай булуы да мөмкин. Күрәсең, мин картайдым ич, колаклар да начар ишетәләр, менә шуңа күрә буташтырганмын.

Алла башка беркемне дә гаепләп булмаячакны күрә, ә Ильядан нәрсә сорыйсың? Үтенечне алып, әйләндереп-әйләндереп карый да Мефодийга:

— Яз минем исемнән резолюция: «нәтиҗәсез калдырырга» диген.

Мефодий резолюцияне язган, алла кул кую урынына тәре билгесе ясаган да старостага биргән.

Староста борылып Толвуйга киткән.

Ул Толвуй мужиклары янына кайта да резолюцияле үтенечне аларга бирә. Мужиклар укып баш селкеп торганнар. Шуннан бирле алар Миколага инде ышанмый башлаганнар.



ЭТ ТОРМЫШЫ

Литва әкияте

Көннәрдән бер көнне алла авыл буйлап бара икән, шул чагында эт өрергә тотынган моңарга.

Алла аңарга:

— Нигә миңа өрәсең? Мин бит синең дөньяга яратучың,— ди икән.

Эт тә җавапсыз калмаган.

— Күрәсең, мине яратканда эшең булмагандыр. Дөньяга туганыңнан тумаганың артык: тумаган булсам, салкында, яңгырда йөреп болай интекмәгән дә булыр идем,— дигән.



«БИР» ДИП ӘЙТМӘ

Кабардин әкияте

Бер крестьян мулланың суга батканын күрә. Ул яр кырыена йөгереп килә дә кулын сузып кычкыра:

— Мулла абзый, тизрәк кулыңны бир! Бир, тизрәк кулыңны!

Мулла ярга бик якын булган, ул үзенә сузылган кулны бик җиңел тотып ала алган булыр иде. Ләкин мулла, крестьянның тавышын ишетү белән, бар көченә ярдан еракка таба китә башлаган.

Бу хәлне икенче бер крестьян күреп торган. Ул, муллаларның гадәтен яхшы белгәнгә, мулланы коткарырга теләүче теге крестьянга болай дип кычкырган:

— Әй-әй, юләр! «Бир!» — дип әйтмә: мулла беркемгә бернәрсә дә бирми, ул бар кешедән дә алырга гына белә. Син аңа: — «Мә!» — дип әйт, шулай димәгәндә, мулла үзенең комсызлыгы аркасында, суга батып үләчәк.

Мулланы коткаручы крестьян аңа яңадан кулын суза, һәм бу юлы:

— Мә, мә, мулла абзый! Мә, ал! — ди.

Мулла, бар көченә ярга якынлаша да, үзенә сузган кулны комсызланып, ике куллап бик нык эләктереп ала.

Шулай итеп, суга бата язган мулла үлемнән котылып кала.



ИЗГЕ ИШӘК

Казах әкияте

Көннәрдән бер көнне шәһәргә, аркасына бер капчык сөяк асып, бик карт бер казах килгән, ди. Очраган кешеләрдән ул утильконтора складының кайда икәнлеген сорый икән. Ниһаять, складны тапкан да үлчәүгә бер өем сөяк салган. Үлчәп торучы сөякләргә карый да болай ди икән:

— Товарыңны кире ал, картым,—бу сөякләргә йөз генә ел да түгелдер, алар череп беткәннәр, безнең өчен ярамыйлар.

Картның кәефе киткән, шулай да ни хәл итсен инде — сөякләрне яңадан капчыкка тутыра башлаган, ә үзе болай ди икән:

— Бир миңа бер сум, кадерле начальник, бер сум бирсәң, бу сөякләрнең кемнеке икәнен сөйләп

бирәм. Бир бер сум — үкенмәссең, канәгать булырсың минем хикәямнән.

Юкка гына яраксыз сөякләр күтәреп килгән картны үлчәүче кызганып куйган, кызыгырлык нәрсә ишетергә өметләнмәсә дә, бер сумлык көмеш тәңкә биргән бу моңа.

Карт сөйли башлаган:

— Борын-борын заманда Чу елгасын кичкән җирдә бер изге кеше кабере булган. Аллага гыйбадәт кылучы күп кенә кешеләр ул кабергә киләләр икән. Бу изге исеменнән карт дәрвиш күрәзәлек итә, кешеләрне дәвалый, аларның язмышын алдан әйтеп бирә икән. Дәрвишкә дә, аның шәкерте миңа да сәдаканы бик мул бирәләр иде. Без бик яхшы яши идек. Аңарда мин берничә ел тордым да изге Мәккәгә сәяхәт итәргә булдым. Бервакыт укытучыма:

«Остазым, миңа хәер-фатихаңны бир, изге урыннарга барырга телим»,— дидем.

Дәрвиш хәер-фатихасын бирде һәм, озак җәяү йөреп арымасын, дип, үзенең бердәнбер ишәген бүләк итте. Шулай итеп мин сәяхәткә чыгып киттем.

Сәфәремнең җиденче көнендә, нәкъ төш вакытында, ишәгем абынып егылды да үлеп тә китте. Карт иде шул. Озын юлның җәфасына түзмәде. Ишәк янына утырдым да елый башладым. Чөнки алда торган озын юлның михнәтләре мине куркыта иде. Карасам, миңа таба юлдан атлылар киләләр. Үзенең ишәген һич тә кызганмыйча үтергән икән, димәсеннәр өчен, мин ишәкне тиз генә юлдан читкәрәк өстерәдем дә ташлар белән күмеп куйдым.

Атлылар ишәк кабере янына килеп җиттеләр, минем дәрвиш киемендә икәнлегемне күрделәр дә күз яшьләремнең сәбәбен сораша башладылар.

«Иң якын дустым белән икәү пәйгамбәребез шәһәренә бара идек, менә дустым үлде, мин аның кабере өстендә елап утырам»,—дидем мин аларга.

«Син шулкадәр кайгыргач, дустың бик гадел булган, ахрысы»,— диделәр дә берничә алтын акча ташлап киттеләр болар.

Ял итәргә дә, уйлап алырга да өлгермәдем, карасам, миңа таба зур гына бер төркем халык килә. Якындагы шәһәр кешеләре икән алар. Әле генә минем яннан үтеп киткән атлылар, шәһәргә барып, ерак та түгел бер изге үлгән, дип сөйләгәннәр икән. Шәһәр кешеләре дустым кабере янында минем калуымны сорарга килгәннәр, әгәр мин бу кабер янында торырга калсам, алар күп кенә бүләк бирәчәкләр икән. Моңа кадәр бу шәһәрдә бер генә изге кабер дә булмаган, ди.

Бераз уйлап торгач, мин карт ишәк мәете миңа ярап куяр, кулга үзе керергә торган бәхеттән баш тарту юләрлек булыр иде, дигән карарга килдем. Риза булдым мин.

Минем изгем турында дан бик тиз таралды. Хаҗга килүчеләрнең саны көннән-көн артты. Сәдаканы да бик күп бирәләр.

Берничә ел үтте. Көннәрдән бер көнне шулай иртән көтмәгәндә миңа карт остазым килеп керде дә:

«Синең данлыклы изгең турында мин дә ишеттем, алла каршындагы гөнаһларым кичерелсен дип, аның каберенә дога кылырга килдем. Я әйт, синең изгең кем, бу җиргә ничек килеп чыктың?»— ди.

Мин остазыма дөресен сөйләп бирдем. Ул миңа бик нык ачуланыр дип уйлаган идем, ләкин дәрвиш, минем аркамнан кагып, шаркылдап көләргә тотынды.

Шул вакытта мин аңа элек беркайчан да со-

рарга кыюлыгым җитмәгән сорауны бирергә булдым. Мин аңардан:

«Әйт әле, остазым, син саклый торган кабергә нинди изге күмелгән?»

«Ул синең изгеңнең анасы иде»,— дип җавап бирде миңа остазым дәрвиш көлеп.

ИКЕ МУЛЛА БЕЛӘН БЕР МУЖИК

Татар әкияте

Борын-борын заманда ике мулла белән бер мужик юлга чыкканнар. Барганнар-барганнар да туктаганнар болар бер кунаклыкка, туктагач, ботка пешергәннәр. Боткага күп итеп май салганнар. Ашарга утыргач, мулланың берсе кашыгын алган да:

— Дин-шәригать юлы менә бола-а-а-й килә,— дип, ботка уртасындагы майны үз ягына агызып җибәргән. Икенче мулла моны карап торган да:

— Безнең әтинең тегермәне менә бу якка таба әйләнә торган иде,— дип, майны үз ягына агызган.

Мужик, карап-карап утырган да:

— Менә, муллалар, дөнья дигәнең гел үзгәреп тора, киләчәктә дөнья менә шулай болганыр, дип, табактагы ботканы бөтенләй болгатып бетергән. Муллалар бу юлы мужикны алдый алмаганнар.

Ярар. Икенче көнне болар тагын кунарга туктаганнар. Боларның бер пешкән казлары булган. Кичен йокларга ятканда үзара болар сөйләшкәннәр:

— Кем дә кем иң яхшы төш күрә, иртәгә казны шул ашар.

Иртән торгач, болар үзләренең төшләрен сөйли башлаганнар. Башта беренче мулла сөйләгән:

— Мин,— дигән,— төшемдә яшел чапан, ап-ак чалма киеп намазга киттем,— дигән.

Аның төшен яхшыга юраганнар. Аннары икенче мулла сөйләгән:

— Мин,— дигән,— зур аккош булып, очып киттем,— дигән.

Моның төшен дә яхшыга юраганнар. Инде мужикка чират җиткән. Ул әйткән:

— Сезнең берегез яшел чапан, ап-ак чалма киеп мәчеткә китте, икенчегез аккош булып очып китте: Мин: «Казны урлап китмәсеннәр тагын» дип куркып, аны ашадым да куйдым,— дигән Шулай итеп, ике мулла бер мужикны алдый алмаганнар.



РАВВИН НИЧЕК АЛЛАНЫ АЛДАГАН

Еврей әкияте

Могҗиза остасы дип дан алган бер раввин үз атына утырып каядыр бара икән. Кучеры да бар моның.

Кичкә таба буран күтәрелә. Ат юлдан яза.

Кучер юкка гына юл эзләгән. Кырда үләрмен дә, кар астына күмелеп калырмын, дигән уй раввинны бик куркыткан.

— И, Авраам, Исаак һәм Иаков алласы, үзеңнең тыйнак колыңны коткарсана,— дип, кайнар яшьләрен түгә-түгә ялварган раввин.— Әгәр дә өемә исән-сау кайтсам, атымны сатып, акчасын ярлыларга өләшер идем,— дигән ул.

Ерак түгел генә юлдан үтеп баручы крестьяннар моның тавышын ишеткәннәр дә ярдәмгә кил-

гәннәр. Алар атны көрттән тартып чыгаралар, юл күрсәтәләр.

Өйгә исән-сау кайтып җиткәч, раввин кучерына атны базарга илтеп сатарга кушкан. Ул аңа этәч биргән һәм атны этәчсез сатмаска боерган.

Кучердан, ат күпме тора дип сорагач, атны этәчсез сатмыйм, ат бер сум, ә этәч йөз сум тора дип җавап биргән. Кешеләрнең исләре киткән, ләкин нәселле, көр ат йөз сумнан артык торганлыктан, берәү этәчне дә, атны да сатып алган.

Ат өчен алынган бер сумны раввин, аллага нәзер әйткәнчә, ярлыларга өләшкән, этәч сатудан килгән акчаны кесәсенә салып куйган.



МУЛЛА НАСРЕТДИН ТУРЫНДА

Көнчыгыш әкияте

Насретдин яшәгән шәһәрдә бер байның яраткан хезмәтчесе үлгән. Бай зур кайгыга төшкән. Мулла Насретдин да бик елаган. Ул, атына атланып, бай янына ашыккан. Юлда аның бер танышы, хезмәтче түгел, байның үзе үлүен әйткән. Шунда Насретдин атын борган да:


— Монысы башка эш. Ул вакытта инде баруның кирәге юк. Мин, байның кайгысын уртаклашып, яхшылык күрсәтмәкче идем. Әгәр ул үзе үлгән икән, мин анда нәрсәгә барыйм,— дигән.

* * *

Көннәрдән бер көнне Насретдинның ишәге үлгән. Ул, ишек төбенә утырып, үкси-үкси елый икән. Мәхәллә кешеләре аны юатмакчы булганнар.

— Алла сиңа ишәкнең яхшырагын бирер,— дигән арадан берсе.

— Көтеп тор! Бик яхшы беләм мин ул алланы: иң начар ишәкне дә ун тәңкәдән дә кимгә бирми ул,— дигән Насретдин.



АЛТЫН ГРАМОТА

Украин әкияте

Мужиклар шулай бер вакытны панга ел буе кое казыганнар икән, ә су һаман чыкмаган. Бик тирән төшкәч, изге Маркин көнендә — 25 октябрьда — болар алтын грамота табалар.

Күп нәрсә язылмаган була бу алтын грамотада. Ул грамотаның хәрефләре кояштай балкыйлар, ә анда язылганны укып чыгучы юк, мужиклар әлифне таяк дип тә белмиләр икән. Грамотаны укытыр өчен, болар тотканнар да паннарына киткәннәр.

Мужиклар, пан утарына килсәләр, ни күрсеннәр: аның ялчылары, панга эшне аз эшләгәнсез, дип, крестьяннарны камчылар белән суктыралар.

Шунда ук зур өстәл артында башка паннар утыралар. Аларның йөзләре кәефле, үзләре симез, өсләрендә яхшы киемнәр, ди.

Пан янына килгәч, мужиклар, бүрекләрен салып, аңа башияләр.

Алтын грамотаны пан мужикларның кулыннан алган да башта үзе укыган, аннары теге паннарга — үзенең кунакларына — биргән, ди. Алары, Алтын грамотаны укып, эчләрен тота-тота шаркылдап көләләр, үзара ниндидер аңлаешсыз сүзләр сөйләшәләр икән.

Алтын грамотадан паннар озак көлгәннәр, ә мужиклар җавапны бик озак көткәннәр. Соңыннан пан мужикларга болай дигән:

— Мужиклар, тыңлагыз. Бу Алтын грамота чыннан да күктән иңгән икән. Тыңлагыз әле, сезгә, мужикларга, алла үзе нәрсә дигән монда... Бу грамотада болай язылган: һавадагы йолдызлар һәммәсе дә бертигез булмаган кебек — аларның кечкенәләре дә, зурлары да бар — җирдә дә кешеләр тигез түгел. Алла һәр кешегә үзенә күрә сәләт биргән. Мужикның алла биргән сәләте — үзенең панына буйсынып эшләү. Мужик үз панына эшләсә, алла аны ярата дигән.

Пан тагын озак сөйләгән. Мужиклар аның дөрес сөйләмәвен, алдавын сизеп алганнар. Алтын грамотада бөтенләй башка нәрсә язылган. Ыгы-зыгы киләләр мужиклар, кычкырышалар, паннан Алтын грамотаны кире бирүен сорыйлар. Бик ачуланган пан бар көченә мужикларга акыра, аяклары белән җиргә тибә, ди. Менә хезмәтчеләр йөгереп килгәннәр. Алар куркынган мужикларны таяклар белән, камчылар белән кыйнарга тотынганнар.

Мужиклар кая туры килсә, шунда качканнар. Яңадан бергә җыелгач, күрәләр: Алтын грамота

тагын аларда була. Аның мужикларга аңлашылмаган хәрефләре кояш кебек балкыйлар.

Мужиклар баралар, баралар да, урядникның укый-яза белгәнлеге исләренә төшә боларның. Алар, озак уйлап тормыйча, туп-туры урядник янына барырга булалар.

Мужиклар, урядник йортына килсәләр, ни күрсеннәр, тегенең ялчылары берәр нәрсә белән начальникларына ошамаган кешеләрне камчылар белән кыйныйлар.

Бер заманны урядник үзе килеп чыга, ди. Аның белән бергә башка урядниклар да булалар. Аларының йөзләре кәефле, үзләре симез, күкрәкләрендә тәреләр, медальләр, билләрендә кылычлар, револьверлар, ди боларның.

Бүрекләрен салганнар мужиклар, урядникның аягына кадәр башларын игәннәр.

Алтын грамотаны урядник мужиклар кулыннан алган да, башта үзе укыган, аннан соң теге урядникларга — үзенең кунакларына — биргән. Тегеләре Алтын грамотаны укыйлар, эчләрен тотатота шаркылдап көләләр, үзара ниндидер аңлаешсыз сүзләр сөйләшәләр. Урядниклар Алтын грамотадан озак көлгәннәр, ә мужиклар җавапны бик озак көткәннәр. Ниһаять, мужикларга урядник болай дигән:

— Мужиклар, тыңлагыз. Бу Алтын грамота чыннан да күктән иңгән икән. Тыңлагыз, сезгә, мужикларга, алла үзе нәрсә дигән монда: «Мужиклар, үзегезнең начальникларыгызга намус белән, түбәнчелек белән буйсыныгыз. Хакимлек алла тарафыннан җибәрелә. Кем дә кем хакимнәр властена буйсынмый икән — ул алланың үзен тыңламый булып чыга!»

Урядник тагын озак сөйләгән, ләкин мужиклар аның дөрес сөйләмәвен, алдавын сизеп алган-

нар. Алтын грамотага язылганның бөтенләй кересен сөйли икән бу.

Кычкырышалар мужиклар, ыгы-зыгы киләләр.

Урядник мужикларга бик нык ачуланган. Аларга бар көченә кычкыра, аяклары белән җиргә тибә, ди. Менә йөгереп килгәннәр аның хезмәтчеләре. Куркынган мужикларга ташланганнар да аларны рәхимсез кыйнарга тотынганнар. Мужиклар кайда туры килсә, шунда качып беткәннәр. Яңадан җыелгач, күрәләр: аларның кулларында тагын Алтын грамота була. Аның хәрефләре кояш кебек балкыйлар.

Мужиклар баралар, баралар да, тагын попның укый-яза белгәнлеген исләренә төшерәләр болар. Дөреслек турында сорарга попка бармыйча, кемгә барырга инде, дип уйлыйлар. Тоталар да поп янына китәләр болар.

Алар поп йортына килсәләр, анда бик күп халыкның мәш килеп торуын күрәләр. Хатын-кызлар тукыйлар, эрлиләр, карчыклар тәрәшле ясап азапланалар, поп кызларының мендәрләре өчен йон йолкалар, аны сайлыйлар. Ирләр күп төрле каралтылар коралар; ә егетләр терлекләр янында кайнаша. Бар да эшлиләр, ә аларны попның камчылы хезмәтчеләре күзәтеп торалар. Хезмәтчеләрнең эшләүче кешеләргә икмәк урынына — таш, су урынына — тозлы су бирүләрен күрәләр мужиклар.

Кешеләр эсседән, ачлыктан һәм сусаудан ыңгырашалар, ә эшләренең очы-кырые күренми. Бер заман баскычта поп үзе күренә. Аның янында бик күп башка поплар да бар. Поплар шундый юаннар, тазалар, йөзләре көләч, өсләрендә хәтфә, ефәк киемнәр. Һәрберсенең күкрәгендә алтын тәре.

Мужиклар баскыч янына килгәннәр, бүреклә-

рен салганнар да, билләренә кадәр бөкрәеп, попларга башларын игәннәр.

Алтын грамотаны поп мужиклар кулыннан алган да, башта үзе укыган, аннан соң башка попларга — үзенең кунакларына — биргән. Тегеләре Алтын грамотаны укыйлар, эчләрен тотып шаркылдап көләләр, ди. Үзара ниндидер аңлаешсыз сүзләр сөйләшәләр. Алтын грамотадан поплар озак көлгәннәр, ә мужиклар җавапны бик озак көткәннәр. Ниһаять, поп мужикларга болай дигән:

— Алла коллары, тыңлагыз. Бу Алтын грамота чыннан да күктән иңгән икән. Тыңлагыз, алла коллары, алла үзе сезгә нәрсә ди монда: «Җирдә елап яшәүчеләр күктә шатланырлар. Кеше түбәнчелек белән аллага гыйбадәт кылырга тиеш, үзегезнең дошманнарыгызны яратыгыз, үзегезне җәберләүчеләргә фатиха бирегез. Әгәр дә берәү синең бер яңагыңа сукса, син аңа икенчесен дә куй, чикмәнеңне алырга теләүчегә күлмәгеңне дә салып бир».

Поп озак сөйләгән, ләкин мужиклар аның дөрес сөйләмәвен, алдавын сизеп алганнар. Алтын грамотада бөтенләй язылмаганны сөйли икән ул.

— Ыгы-зыгы киләләр мужиклар, кычкырышырга тотыналар, поптан Алтын грамотаны кайтарып бирүен таләп итәләр.

Ачуланган поп мужикларга акыра, аяклары белән җиргә тибә, ди. Шул вакыт килеп җиткән попның хезмәтчеләре. Алар куркынган мужикларга ташланганнар, камчылар, таяклар белән рәхимсез кыйнарга тотынганнар. Мужиклар кая туры килсә, шунда качып бетәләр. Яңадан бергә җыелгач, күрәләр: Алтын грамота тагын аларда була. Аның мужикларга аңлашылмый торган хәрефләре һаман кояш кебек балкыйлар.

Алтын грамота белән кая барырга да белми аптырап торалар мужиклар. Кояш кебек балкып торган андагы хәрефләрне кем укып бирсен соң аларга?

Шушы юлдан Ленин үтеп бара икән. Мужиклар Ленинны урап алганнар да Алтын грамотаны укып бирүен сорыйлар, ди, аңардан.

Ленин, мужиклар кулыннан Алтын грамотаны алган да, аны укып чыккач, көлемсерәп болай ди икән:

— Дусларым минем, мин бу Алтын грамотаны Сезгә укып бирермен, ләкин ул гына аз булыр. Сезнең үзегезгә дә мондый грамоталарны укырга өйрәнергә кирәк.

Мужиклар Ленинга рәхмәт әйтәләр, авылларына килеп, аларны грамотага өйрәтүен сорыйлар.

Ленин авылда озак та тормаган, ди, мужиклар укырга-язарга өйрәнгәннәр. Алтын грамотаны укып чыккач, бик дулкынланганнар, ди, үзара шыпырт кына сөйләшәләр икән алар. Тиздән алар үзләренең крестьян комитетына оешканнар, кемгә нәрсә туры килде, шуның белән коралланып, работниклар, башка кораллы кешеләр белән бергә үзләренең дошманнарын: патшаны, попны, пан-алпавытларны бетергәннәр, ди, Алтын грамотада язылганча тора башлаганнар.

Алтын грамотада бары бер генә сүз — **Коммунизм** дигән сүз язылган була.

ЭЧТӘЛЕК

Кәҗә тәкәсен күмү. *Ф. Мостафин тәрҗемәсе* . 5
Поп белән Пономарь. *Ф. Мостафин тәрҗемәсе* 9
Шахсевен хаҗиеның эте. *К. Сабиров тәрҗемәсе* 11
Мужик ничек оҗмахка барган. *Ф. Мостафин тәрҗемәсе* 14
Эт тормышы. *Ф. Мостафин тәрҗемәсе* 20
„Бир" дип әйтмә. *С. Урайский тәрҗемәсе* . . 21
Изге ишәк. *Ф. Мостафин тәрҗемәсе* 23
Ике мулла белән бер мужик. 27
Раввин ничек алланы алдаган. *Ф. Мостафин тәрҗемәсе* 29
Мулла Насретдин турында. *Ф. Мостафин тәрҗемәсе* 31
Алтын грамота. *Ф. Мостафин тәрҗемәсе* . . 33

ЗОЛОТАЯ ГРАМОТА

Сказки народов СССР

(на татарском языке)

Техник редакторы *Ф. Г. Нурутдинов*
Художество редакторы *Э. Е. Дьячкова*
Корректоры *М. Ш. Шакирова*

Наборга бирелде 30|IV-1955 ел. Басарга кул куелды 3/VI-1955 ел. ПФ 02284.
Кәгазь форматы $84 \times 103^1/_{32}$. Учет-изд. 1,1 табак. Басма табак 2,5(2,05).
Табакта 44.000 хәреф. Заказ № 0173. Тираж 8000. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Культура Министрлыгының Татполиграф типографиясе.
Казан, Миславский ур., йорт № 9.

Бәясе 40 тиен